БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«20» 09 2024 ел

**КАРАР**
№ 233

2025 елга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге «Татарстан Республикасының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 854 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 2025 елга расларга:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының кушымта итеп бирелгән балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны, 1 нче кушымта нигезендә;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга төзәтмә коэффициентын 0,75 кә тигез итеп.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында http://baltasi.tatarstan.ru адресы буенча халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2023 елның «20» 09
233 номерлы карары нигезендә расланган
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашуы | Норматив чыгымнар (бер укучыга бер елга сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | җиде еллык уку вакыты | Башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыкаль сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 78 737 | 89 952 | 115 527 |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 83 699 | 95 607 | 122 722 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 41 684 | | 37 010 | 88 817 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 44 232 | | 39 296 | 94 291 |
| Бию сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 87 814 | 72 312 | 265 068 |
| Бию сәнгате | авыл җирлеге | | | 93 401 | 76 913 | 281 919 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 36 926 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 39 265 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 80 741 | 77 524 | 124 555 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 85 893 | 82 475 | 132 470 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 121 586 | | 116 554 | | 191 128 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 129 245 | | 123 915 | | 203 145 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 62 682 | | 58 352 | 58 267 | 87 898 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 66 606 | | 62 016 | 61 926 | 93 302 |